Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советының кырык тугызынчы утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

5 декабрь, 2024 ел № 371

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 19 апрелендәге 38 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карары белән (Питрәч муниципаль районы Советының 2017 елның 13 июлендәге 101 номерлы, 2017 елның 14 сентябрендәге 111 номерлы, 2018 елның 26 апрелендәге 141 номерлы, 2018 елның 24 октябрендәге 164 номерлы, 2019 елның 28 февралендәге 184 номерлы, 2019 елның 25 июлендәге 212 номерлы, 2020 елның 26 мартындагы 249 номерлы, 2020 елның 14 маендагы 263 номерлы, 2021 елның 22 мартындагы 251 номерлы, 2021 елның 22 маендагы 251 елның 22 августындагы 323 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Муниципаль хезмәткәрнең төп бурычлары» 3.3 өлешенең 3.3.1 пунктының 12 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) анкетадагы белешмәләргә үзенә билгеле булган үзгәрешләр турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә (үзгәрешләре яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары белән булган белешмәләрдән тыш, муниципаль хезмәткәргә әлеге үзгәрешләр турында билгеле булган көннән алып, аның вакытлыча эшкә яраксызлыгы, ялда булу, хезмәт вакытын исәпкә алмаганда, 10 эш көне эчендә командировкага китү, нигезле сәбәпләр аркасында хезмәттә булмауның башка очраклары, әгәр федераль законнарда башка срок билгеләнмәгән булса, формасы буенча, Россия Федерациясе Президентының 2024 елның 10 октябрендәге 870 номерлы Указының 1 пунктындагы «в» пунктчасында каралган (алга таба – анкетадагы белешмәләр).».

1.2. «анкета тапшыру, анкетада булган белешмәләрне үзгәртү турында хәбәр итү һәм мондый белешмәләрне тикшерү» сүзләрен «әлеге Нигезләмәнең 3.3.1 өлешендәге 12 пунктындагы 3.3.1 пунктчасында каралган» сүзләренә алмаштырырга.

1.3. «Муниципаль хезмәткә керешү» 4.1 өлешендәге 4.1.3 пунктының 5 пунктчасында «Мәгариф турында» сүзләреннән соң «квалификация турында» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов